**Каралды**
**Методик берләшмә җитәкчесе**
**______ Рамазанова Р.Н.**
**Беркетмә № 1**
**25 нче август 2017 нче ел**

**Килешенде**
**Уку-укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**______ Г.Т.Исмагилова**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**________ Г.Т.Сабирзянова**
**Приказ № 71**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Татарстан Республикасы муниципаль гомуми**
**белем бирү бюджет учреждениесе**
**Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Рамазанова Раушания Наил кызының**
**5 нче Б,В.сыйныфы өчен татар теленнән**

# ***ЭШ ПРОГРАММАСЫ***

**Педсовет утырышында каралды**

**Беркетмә № 1 28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

АННОТАЦИЯ

Федераль дәүләт стандартларына туры китерелеп 5 нче сыйныфта татар әдәбияты дәресләренә эш программасы түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1.”Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы(2004нче ел, 1нче июль)
2. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь).
3. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”). 4. ”Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа ” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
5.Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.

Эш программасы стандарттагы минимумга нигезләнеп төзелде.

Укыту планында 5нче сыйныфта татар телен өйрәнүгә атнага 3 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән эш программасы “Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа”га (М.З.Зәкиев, К.З.Зиннәтуллина, С.М. Ибраһимов, Н.В.Максимов. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010) нигезләнеп төзелде.

**Дәреслек.** .“Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек/ Ч.М. Харисова,Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов.- Казан, Мәгариф, 2012).

**Сыйныф:** *5*
**Укытучы**: Рамазанова Раушания Наил кызы

**Сәгатьләр саны:**

Атнага – 3 сәгать (елына – 105 сәгать).
Диктант язу – 5 сәгать ;
Изложение язу – 4 сәгать (барысы – 4 изложение, икесе – контроль изложение);
Сочинение язу – 4 сәгать (барысы – 4 сочинение, 2– контроль сочинение) + өй сочинениеләре.

**Планлаштыру** "Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа", V - IX сыйныфлар өчен, Г. Р.Галиуллина, М.М.Шәкүровалар авторлыгында, 2013 ел

**Дәреслек:** “Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек/ Ч.М. Харисова,Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов.- Казан, Мәгариф, 2012).

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныф өчен " Татар теле" курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан расланган үрнәк программа ("Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа", V - IX сыйныфлар өчен, Г. Р.Галиуллина, М.М.Шәкүровалар авторлыгында, 2013 ел), Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законына (2007 нче ел, 1 нче декабрь), МБББУ "Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең эш программасы турында нигезләмәсенә, МБББУ "Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең 2017-2018 нче уку елына укыту планына, "Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек/ Ч.М. Харисова,Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов.- Казан, Мәгариф, 2012). Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

**Татар теленнән белем бирүнең төп максаты:**

- Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәни) компетенцияләр булдыру.
- Укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү.

## Бурычлары:

- Укучыларның башлангыч мәктәптә фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү.
- Укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү.
- Телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү.
- Татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү, сөйләмэшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлату.
- Баланың үзен тәрбияләү, үзе белән идарә итү, үз фикерен яклый алу сәләтен үстерү.
- Укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү.
- Җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләренә, әхлак нормаларына төшендерү.
- Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.
- Сөйләм культурасы булдыру.

**"Татар теле" курсына гомуми характеристика**

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Закон нигезендә федераль дәүләт белем стандартына туры китереп, мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле һәм әдәби уку аерым өйрәтелә, сәгатьләр саны рус теле һәм әдәбиятын өйрәнү күләменә якынайтыла. Программа белем һәм тәрбия бирү ана телендә алып барыла торган мәктәпләрдә укучы татар балаларының татар телен яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, аларны киләчәк баскычларда зуррак белем алуга әзерли.

Татар теле программасы белем һәм тәрбия бирү ана телендә алып барыла торган сыйныфларда укучы татар балаларына татар телен аралашу һәм татар халкының әдәбияты, сәнгате, тарихы, мәдәнияте белән таныштыру чарасы буларак укытуны тәэмин итәргә тиеш.

Татар теле –урта сыйныфларда төп гуманитар предметларның берсе, чөнки укучы татар теле ярдәмендә башка предметларны да үзләштерү мөмкинлегенә ия була.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

“Татар теле” курсы “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесенең укыту планына кергән. “Татар теле” предметы ФДББС буенча атнасына 5 нче сыйныфта – 3 сәгать. Мәктәптә татар теле предметы әһәмиятле предметларның берсе. Татар мәктәпләрендә татар балаларына татар телен өйрәтү үз телләрен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уятуга, мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный.

## Уку предметы эчтәлегенең кыйммәти юнәлешләре

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбендә ана телен өйрәтү телнең төрле катламнарына караган теоретик материалны өйрәтү белән бергә, татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен камил куллана белергә, ана теленең сыгылмалылыгын, аралашу процессында ачыла торган нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен өйрәтүне дә күздә тота. Татар мәктәпләрендә татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме — аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, заманча технологияләрне файдаланып, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә, мәдәният белән бәйләнешенә игътибар бирүне дә таләп итә. Гражданлык, гаилә, сәнгать, матурлык кебек кыйммәтләр системасы һәр дәреснең нигезенә салынган. Бу кыйммәтләр уку программасына кертелгән һәр әсәрдә чагылыш таба.
Тормыш кыйммәтләре- кеше тормышын, гомерен иң зур кыйммәт итеп тану;
Яхшылык кыйммәтләре- кешеләргә карата шәфкатьле, мәрхәмәтле, рәхимлеле булу;
Иреклелек кыйммәтләре- кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең нигезе булуын тану;
Табигать кыйммәтләре- үзеңнең табигатьнең бер өлеше булуын белү; табигатьне ярату, аның матурлыгын, камиллеген саклау;
Матурлык кыйммәтләре- сәнгатьнең бер төре булган әдәбиятка тарту аша, зәвык тәрбияләү;
Гаилә кыйммәтләре- кеше үсеше өчен иң мөһим тирәлекне күрү;
Хезмәт һәм иҗат кыйммәтләре- оешканлык, максатчанлык, җаваплылык, мөстәкыйльлек сыйфатлары формалаштыру;
Гражданлык кыйммәтләре- үзеңне җәмгыятьнең, халыкның, илнең, дәүләтнең бер өлеше итеп тану; илнең бүгенгесе, киләчәге өчен җаваплылык хисе тою.
Патриотлык кыйммәтләре- Татарстан дәүләтенә хезмәт итәргә әзер булу;
Кешелеклелек кыйммәтләре- ярдәмләшү, үзара хөрмәт, толерантлык хисләре тәрбияләү;
Аралашу кыйммәтләре- мәдәният үсеше өчен аралашуның мөһимлееген аңлау.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- Мөстәкыйль, бәйләгеч, модаль сүз төркемнәрен таба белү, аларның морфологик үзенчәлекләрен билгели алу.
- Морфологик анализ ясау үзенчәлекләрен үзләштерү.
- Синтаксик анализ ясау элементларын үзләштерү.
- Морфологик закончалыкларны күрә белү.
- Сүзне катлаулы тел берәмлеге буларак бәяләүгә ирешү.
- Укылган текстның эчтәлеген аңлау, үз мөнәсәбәтеңне белдерү.
- Укылган текстка бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү.
- Сыйныфташлары һәм укытучы белән фикер алышу, үз фикерен дәлилле белү.

- Тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү.
- Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләрен аера белү һәм урынлы куллану.

**Күнекмәләргә таләпләр: (уку елы башында):**

- өйрәнелгән сүз төркемнәрен бер-берсеннән аера һәм аларның үзенчәлекләрен аңлата белү;
- 45-60 сүздән торган12-20 җөмләле текстны дөрес итеп күчереп язу;
- фонетик, лексик, грамматик биремле күнегүләрне башкару;
- укылган (тыңланган) текстка карата сораулар куя белү, текст эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә алу;
- зур булмаган текстның эчтәлеген сөйләү;
- диалогик һәм монологик формада аралашу күнекмәләрнә ия булу;
- төрле төрдәге диктант, изложение, сочинение язу;
- көндәлек аралашуга бәйле татар сөйләм этикеты формаларын дөрес куллану;
- татар теленең орфоэпик нормалары нигезендә аралаша алу;
- тел чараларының төрле жанрдагы әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен күрә белү;
- татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белү, сөйләм барышында ике тел чараларын бутамау;
- татар теленнән алган белемне башка фәннәрне үзләштерүдә файдалана белү. Бер минутка 110-120 сүздән торган текстны дөрес итеп укый, эчтәлеген аңлый һәм сөйли алу; чиста һәм матур итеп80 билге (хәреф) яза белү.

**Күнекмәләргә таләпләр (уку елы ахырына)**

- сузык һәм тартык авазлар арасындагы аерманы аңлату; о, ы, ә, я, ю, е, ё, в, к, г хәрефләре белдергән авазларга аңлатма бирү; ул хәрефләрне һәм ь, ъ хәрефләренең язылышын аңлату; сузык һәм тартык авазларга хас булган фонетик законнар күзәтелгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу;
- өйрәнелгән темаларга бәйле рәвештә сүзләргә фонетик һәм лексик анализ ясау, аларга төзелеше һәм ясалышы ягыннан характеристика бирү; гади җөмләләргә синтаксик анализ ясау; бирелгән үрнәкләргә нигезләнеп, гади һәм кушма җөмләләр төзи белү;
- бирелгән таныш сүзләрнең мәгънәләрен аңлату; башлангыч сыйныфта өйрәнгәннәрне истә тотып, өйрәнелгән орфограммаларны табу; җөмләдәге сүзләрнең язылышын аңлату, җөмлә ахырында һәм кушма җөмләдә тиешле тыныш билгеләрен кую;
- татар теленең үз сүзләрен һәм алынма сүзләрне аеру, мәгънәләрен аңлау; төрле сүзлекләрдән файдалана белү; фрезеологик әйтелмәләрнең мәгънәләрен аңлау;
- сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен табу һәм аларга аңлатма бирү, аларны шартлы билгеләр белән күрсәтү; ясалышы ягыннан төрләрен билгеләү;
- текстның темасын һәм төп фикерен аңлау, гади план төзеп, эчтәлеген сөйләү; сочинение һәм изложение язу; телдән һәм язма сөйләмдә фикерләрне тәэсирлерәк итеп белдерү өчен, синонимнарны файдалана белү;
- эш кәгазьләре төрләреннән хат, мәкалә, белешмә яза белү.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:***

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртергә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

***Танып-белү гамәлләре:***

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

***Коммуникатив УУГ:***

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

***Регулятив УУГ:***

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;

- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

***Предмет нәтиҗәләр:***

- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- исем, фигыль, зат алмашлыкларын табарга өйрәтү, аларның морфологик үзенчәлекләрен һәм җөмләдә кулланылышын аңлау;
- сүз төркемнәрен дөрес язу, аларны сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү;
- сүзтезмәләрне аера белү, алардагы ияртүче һәм ияручe сүзне билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтү;
- морфологик, синтаксик анализ ясау элементларын үзләштерү;
- телдән һәм язма сөйләмне синонимнар, фразеологизмнар белән баету, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрдән дөрес файдалана белү, сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен урынлы куллану;
- төрле телләрдән кергән сүзләрнең мәгънәләрен аңлап куллану һәм дөрес әйтү күнекмәләре булдыру;
- сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыруны дәвам итү;
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксынды

**Уку предметы эчтәлеге**

| № | Төп темалар | Сәгать | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | Тел кешене дус итә | 1 | Татар теле турында гомуми мәгълүмат. |
| 2. | Башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау һәм ныгыту. | 3 | Тел гыйлеменең төп бүлекләре. Җөмлә кисәкләре, гади җөмләнең төрләре. |
| 3. | Морфология | 22 | Сүз төркемнәре һәм аларның морфологик билгеләрен таны белү, телдән язма сөйләмдәге рольләрен аңлау, аларны , орфографик һәм грамматик кагыйдәләргә нигезләнеп , дөрес язу.лизы ясый белү |
| 4. | Синтаксис һәм пунктуация | 18 | Баш һәм иярчен кисәкләрне таба белү,сүзләрне өлешчә-морфологик, синтаксик һәм пунктуацион яктан тикшерү. |
| 5. | Фонетика, орфоэпия һәм орфография | 10+2 | Сузык һәм тартык авазларны ишетеп аера белү, дөрес әйтә һәм яза белү.Сүзләргә хәреф-аваз анализы ясый белү. Татар телендәге төп орфографик кагыйдәләр белән танышу, дөрес язарга өйрәнү. |
| 6. | Лексика һәм сөйләм культурасы | 14+1 | Сөйләмне туры һәм күчерелмә мәгънәдәге сүзләр, синоним, антоним һәм фразеологизмнар белән баету.Башка телләрдән кергән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сүзләрне дөрес әйтү, язу һәм мәгънәләрен аңлау.Сүзне төзелеше ягыннан тикшерә белү күнекмәләре булдыру. |
| 9. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 34 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү. |

**Искәрмә.**«Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 5 нче Б сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә.

**Календарь - тематик план**

| № | Дәрес темасы | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **План** | **Факт** |
| 1 | Тел – кешеләрнең үзара аралашу чарасы | Кереш сүз, әңгәмә. Сораулар буенча төркемнәрдә эш. Терәк схема ясау. | 02.09БВ | |
| 2 | Морфология, орфография һәм сүз төркемнәре турында төшенчә. | Күнегүләр эшләү. Сүз төркемнәрен кабатлау. Җөмлә кисәкләрен кабатлау. | 05.09Б<br>04.09В | |
| 3 | Аваз һәм хәрефләр. | Аваз һәм хәрефләр турында кабатлау. | 07.09Б<br>06.09В | |
| 4 | Сузык һәм тартык авазлар | Сузык һәм тартык авазларны ишетеп аера белү, дөрес әйтә һәм яза белү.Сүзләргә хәреф-аваз анализы ясый белү. Татар телендәге төп орфографик кагыйдәләр белән танышу, дөрес язарга өйрәнү. | 09.09БВ | |
| 5 | Уку елы башында үткәрелә торган контроль эш (диктант № 1)”Тургай” | Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемәрен искә төшерү | 12.09Б<br>11.09В | |
| 6 | Б.С.Ү.Сочинение ”Мин җәйге каникулларны ничек үткәрдем?” | Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемәрен искә төшерү | 14.09Б<br>13.09В | |
| 7 | Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә | Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемәрен искә төшерү | 16.09БВ | |
| 8-9 | Исем.Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне аера белү өчен күнегүләр эшләү | 19.09Б<br>18.09В<br>21.09Б<br>20.09В | |
| 10 | Исемнәрнең берлек һәм күплек төре | Исемнең терәк схема сын ясау. Күнегүләр эшләү. | 23.09БВ | |
| 11 | Исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. | Килеш сорауларын һәм кушымчаларын дөрес билгеләргә өйрәнү. | 26.09Б<br>25.09В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | “Исем” темасын ныгыту буенча күрмә изложение | Хикәянең эчтәлеге буенча план төзү. Изложение язу. Исемнәрнең килешләрен күрсәтү. | 28.09Б<br>27.09В | |
| 13 | Зат алмашлыгы. | Алмашлык турында аңлату, нинди сүз төркемен алмаштырып<br>килүдән чыгып, төркемчәләргә бүлү. Күнегүләр эшләү. | 30.09БВ | |
| 14 | Сорау алмашлыклары | Сорау алмашлыкларының килеш белән төрләнешен аңлату,<br>күнегүләр эшләү | 03.10Б<br>02.10В | |
| 15-16 | Сан. Төрләнми торган сүз төркеме | Күнегүләр эшләү. | 05.10Б<br>04.10В<br>07.10БВ | |
| 17-18 | Сыйфат.<br>Антоним һәм синоним сыйфатлар | Лексика бүлеген искә төшерү: антоним, синоним, искергән сүзләр буенча күнегүләр эшләү | 10.10Б<br>09.09В<br>12.10Б<br>11.09В | |
| 19 | **БСҮ . Изложение № 1. “Күңелле өмә”** | Хикәянең эчтәлеге буенча план<br>төзү.Изложениеязу.Исемнәрнең<br>килешләрен күрсәтү. | 14.10БВ | |
| 20 | Хаталар өстендә эш.Фигыль турында гомуми төшенчә.Барлык-юклык төре. | Эшнең башкарылу- башкарылмавыннан чыгып, барлык-юклык<br>төрен аңлату,телдән күнегүләр эшләү. | 17.10Б<br>16.09В | |
| 21 | Фигыльнең нигезе. | 81 нче күнегүдәге рәсем буенча эшләү. | 19.10Б<br>18.09В | |
| 22 | Боерык фигыль. | План буенча хикәянең эчтәлеген сөйләү. | 21.10БВ | |
| 23 | Хикәя фигыль. | «Казан – спорт шәһәре” дигән темага кечкенә хикәя язу. | 24.10Б<br>23.10В | |
| 24 | Шарт фигыль | Күнегүләр эшләү | 26.10Б<br>25.10В | |
| 25 | “Фигыль” темасын ныгыту. | Күнегүләр эшләү | 28.10БВ | |
| 26 | Контроль диктант № 2. “Сак булыгыз” | Диктант язу | 07.11Б<br>06.11В | |
| 27 | Хаталар өстендә эш | Язма эштә җибәрелгән хаталар өстендә эшләү. Аңлату. | 09.11Б<br>08.11В | |
| 28 | Рәвеш турында төшенчә. Урын һәм вакыт рәвешләре. | Күнегүләр эшләү. Диалог төзетү. | 11.11БВ | |
| 29 | Сәбәп-максат рәвешләре | Хикәянең эчтәлеген сөйләү. | 14.11Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 13.11В | |
| 30 | Рәвеш темасын ныгыту | Күнегүләр эшләү .Авыр очракларны аңлату. | 16.11Б<br>15.11В | |
| 31 | Сүз төркемнәрен кабатлау. | | 18.11БВ | |
| 32-33 | Контроль изложение № 2. “Ноябрь чебешләре” | Укытучы укыганны тыңлау, гади план төзү һәм сөйләп карау.<br>Караламага язу, аака күчерү | 21.11Б<br>20.11В<br>23.11Б<br>22.10В | |
| 34 | Хаталар өстендә эш | Язма эштә җибәрелгән хаталар өстендә эшләү. Рәвешләр турында катлаулы таблица буенча эшләү . | 25.11БВ | |
| 35-36 | Синтаксис һәм пунктуация. Җөмлә турында гомуми төшенчә. | Җөмләләргә синтаксик анализ ясау элементлары белән таныштыру: җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү.<br>Күнегүләр эшләү | 28.11Б<br>27.11В<br>30.11Б<br>29.11В | |
| 37-38 | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре.Хикәя һәм сорау җөмләләр. | Җыйнак җөмләләр, җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү.<br>Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 02.12БВ<br>05.12Б<br>04.12В | |
| 39-40 | Боерык һәм тойгылы җөмләләр | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 07.12Б<br>06.12В<br>09.12БВ | |
| 41 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Хикәя төзү. | Күнегүләр эшләү. “Кем кемгә охшаган” дигән темага хикәя язү. | 12.12Б<br>11.12В | |
| 42-43 | Гади җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 14.12Б<br>13.12В<br>16.12БВ | |
| 44 | Кушма җөмлә. | Күнегүләр эшләү. | 19.12Б<br>18.12В | |
| 45 | Җыйнак җөмлә. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 21.12Б<br>20.12В | |
| 46 | БСҮ Текст, аның темасы. Гади план төзү. | | 23.12БВ | |
| 47<br>48 | Зат алмашлыгы белән белдерелгән анысланмыш | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 09.01Б<br>08.01В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 11.01Б<br>10.01В | |
| 49-50 | Җәенке җөмлә Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 13.01БВ<br>16.01Б<br>15.01В | |
| 51 | Тәмамлык | Аңлату, әңгәмә,җкүнегүләр эшләү | 18.01Б<br><br>17.01В | |
| 52-53 | Хәл | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 20.01БВ<br>23.01Б<br>22.12В | |
| 54 | Мөстәкыйль эш (күнегүләр эшләү) | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 25.01Б<br>24.12В | |
| 55 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. | Күнегүләр эшләү. Карточкалар буенча | 27.01БВ | |
| 56 | Тиңдәш кисәкләре арасында тыныш билгеләре. | Күнегүләр эшләү. | 30.01Б<br>29.01В | |
| 57 | Текст, аның темасы. Гади план төзү | Аңлату, әңгәмә | 01.02Б<br>31.01В | |
| 58 | **БСҮ Сочинение** | Аңлату, әңгәмә | 03.02БВ | |
| 59-60 | Фонетика, орфография. Орфоэпия. Сөйләм органнары. Авазларның ясалышы. | Аңлату, әңгәмә,<br>күнегүләр эшләү | 06.02Б<br>05.02В<br>08.02Б<br>07.02В | |
| 61 | Сузык һәм тартык авазлар таблицасы. | Сузык авазларга характеристика (терәк схема ясау).Күнегүләр эшләү. Тартык авазлар турында катлаулы таблица буенча эшләү, шуңа нигезләнеп, гади таблица ясау | 10.02БВ | |
| 62 | Сингармонизм законы, аның төрләре. | Аңлату, әңгәмә | 13.02Б<br>12.02.В | |
| 63-65 | Сүзләрнең язылышы туры килгән һәм килмәгән очраклары. | Аңлату, әңгәмә.Күнегүләр эшләү. | 15.02Б<br>14.02В<br>17.02БВ<br>20.02Б<br>19.02В | |
| 66-67 | **БСҮ . Изложение № 3. “Керпе”** | Изложение тексты буенча план төзү, язу. | 22.02Б<br>21.02В<br>24.02БВ | |
| 68-69 | Сөйләмдә тартыкларның үзгәреше. | Язма эштә җибәрелгән хаталар өстендә<br>эшләү | 27.02Б<br>26.02В<br>01.03Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 28.02В | |
| 70 | Ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 03.03БВ | |
| 71 | Б.С.Ү. Картина буенча эш | Картина буенча эшләү | 06.03Б<br><br>05.03В | |
| 72 | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | Аңлату, күнегүләр эшләү | 08.03Б<br><br>07.03В | |
| 73 | Контроль диктант №3. “Яңа өйгә күчү” | Диктант язу. | 10.03БВ | |
| 74 | Хаталарны анализлау,төзәтү эше | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 13.03Б<br><br>12.03В | |
| 75 | Лексикология һәм сөйләм культурасы турында төшенчә. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 15.03Б<br>14.03В | |
| 76 | Татар теленең сүз байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе | Аңлату, әңгәмә,күнегүләр эшләү. | 17.03БВ | |
| 77 | БСҮ. Монологик сөйләм. | Аңлату, әңгәмә, | 20.03Б<br><br>19.03В | |
| 78 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 22..03Б<br><br>21.03В | |
| 79 | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 24.03БВ | |
| 80-81 | **Л.Фәттаховның “Сабантуй”картинасы буенча сочинение** | Картина буенча  эшләү | 05.04Б<br>04.03В<br>07.04БВ | |
| 82 | Омонимнар, синонимнар, антонимнар. | Аңлату, күнегүләрэшләү. | 10.04БВ<br><br>09.04В | |
| 83 | Фразеологик әйтелмәләр | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү.Тәрҗемә эше. | 12.04Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 11.04В | |
| 84 | Мәкалә язу | Аңлату, әңгәмә | 14.04БВ | |
| 85-86 | Татар теленең чыгышы ягыннан сүзлек составы. | Аңлату, әңгәмә | 17.04Б<br>16.04В<br>19.04Б<br>18.04В | |
| 87-88 | Татар теленең кулланылыш өлкәсе ягыннан сүзлек составы. | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | 21.04БВ<br>24.04Б<br>23.04В | |
| 89-90 | Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы. | Күнегүләр эшләү. | 26.04Б<br>25.04В<br>28.04БВ | |
| 91 | Хат язу | Аңлату, әңгәмә | 01.05Б<br><br>30.04В | |
| 92-93 | Сүзлекләр, аларның төрләре. Сүзлекләрдән файдалану күнегүләре. | Аңлатмалы һәм орфографик сүзлекләр турында һәм алардан файдалана белергә өйрәтү. Интернет аша турыдан-туры<br>эшләүче (онлайн) һәм цифрлаштырылган сүзлекләр белән таныштыру. | 03.05Б<br>02.05В<br>05.05БВ | |
| 94 | Лексикология бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | Аңлату, күнегүләр эшләү. | 08.05Б<br><br>07.05В | |
| 95-96 | **Контроль сочинение** | Аңлату, әңгәмә | 10.05Б<br><br>09.05В<br><br>12.05БВ | |
| 97 | Хаталарны төзәтү эше | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү. | 15.05Б<br><br>14.05В | |
| 98-99 | **Контроль изложение № 4. “Гөлләр үстерик”** | Изложение тексты буенча план төзү, язу. | 17.05Б<br>16.05В<br>19.05БВ | |
| 100 | Хаталарны анализлау, төзәтү | Аңлату, күнегүләр эшләү. | 22.05Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 21.05В | |
| 101-103 | Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау. | Аңлату, күнегүләр эшләү. | 24.05Б<br>23.05В<br>26.05БВ<br>29.05Б<br>28.05В | |
| 104 | Контроль диктант № 4. “Сертотмас кәҗә” | Диктант язу. | 31.05Б<br>30.05В | |
| 105 | Хаталарны төзәтү эше. Йомгаклау дәресе. | Аңлату,күнегүләр эшләү. | 31.05Б<br>30.05В | |

Укыту-методик комплекты

1.«Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар:1-11”- Казан: Татар.кит.нәшр.,2011.
2.“Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек/ Ч.М. Харисова,Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов.- Казан, Мәгариф, 2012).
3.Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы (Ф.С.Вәлиев, Г.Р.Саттаров. – Казан. “Раннур”, 2000)
4.Хәзерге татар әдәби теле. (Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Казан, “Мәгариф”, 2005)

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (6,7,10,32 маддә).
3. ”Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
5. Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек/Р.А. Юсупов, К.З.Зиннәтуллина, Ч.М. Харисова, Т.М.Гайфуллина.- Казан, Мәгариф, 2006.
6. Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар).
7. Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар).
8. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы, К..: Раннур н-ты, 2000.
9.Татар телендә тыныш билгеләре,Казан ,1985.- Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов, Э.Вафина.
10.Морфология һәм орфография буенча кулланмалар.-Урта мәктәпнең ана теле укытучылары, мәктәп укучылары өчен күрсәтмә әсбаплар./Н.В.Максимов.-“Таң-Заря”, 1997.
14.Татар теленнән 222 тест/-Х.Сәлим.-Казан, “Яңалиф”, 2005.
15.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы, Казан,2003.-Н.Гыймадиева, Р.Нуруллина
16.Интернет ресурслар: tugantelem.narod.ru, qushlawich.ru, gzalilova.narod.ru

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

**<u>Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:</u>**

Сүзлек диктантының күләме –15-20 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант текстының күләме - ел башында 100 сүз, ел ахырында - 110 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме
ел башында 150-170 сүз (110-120- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин)

2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Тестны бәяләү**

1.Тестның 76-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Тестның 61-75% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3.Тестның 51-60% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4.Тестның 0-50% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

**Мөстәкыйль эшне бәяләү**

1. Мөстәкыйль эшнең 75-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Мөстәкыйль эшнең 60-74% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3 Мөстәкыйль эшнең 41-59% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4. Мөстәкыйль эшнең 0-40% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

## Өстәмә материаллар

1. **Диктантлар.**
2. **Тестлар.**
3. **Мөстәкыйль эшләр.**

### Диктантлар.

**Диктант № 1.**

(уку елы башында үткәрелә торган язма эш тексты)

Әле көннәр бик салкын тора. Бөтен җирдә кар ята. Табигатьтә кыш белән яз тартыша. Март кояшы нык яктырта, тик аз җылыта. Шулай да яз җиткәне сизелә. Аның җиткәнен һавада яңгырап ишетелгән тургай тавышы раслый.

Тургай – бездә яз көне иң алдан килүче кошларның берсе. Тургай зур түгел. Ул кара бөрчекле һәм тимгелле коңгырт соры төстә. Җиргә кунгач, шушы төс аны дошманнардан саклый.

Тургай оясын очратсагыз, аннан тизрәк китегез, кошны куркыта күрмәгез ! Шулай итсәгез, икенче язны тургайлар тагын да күбрәк килерләр, басуларны зарарлы бөҗәкләрдән сакларлар, яңгыратып сайрап, кешеләрне шатландырырлар.

(87 сүз)

**Диктант № 2**

Сак булыгыз

Кайчак малайлар урманда кош оясы табалар да анда йомырка күреп сөенәләр, аларны карарга тотыналар. Ә кайберләре хәтта тотып ук карый, кузгата.

Ул вакытта бу ояның кошлары якын-тирәдә генә очып йөри торган була. Алар борчулы тавыш белән кычкыралар. Әмма малайлар моңа игътибар бирми. Алар инде үзләрнең берничә кош баласын һәлак иткәнлекләрен башларына да китермиләр.

Ә кошлар бүтән бу ояга килмәячәк. Чөнки алар ояга кагылучының үзен күрмәсәләр дә, үләндәге эзен, сынган куак ботакларын күрәләр. Барыбер беләчәкләр, бу ояны ташлаячаклар. Бу җәһәттән ясмык чыпчыгы белән кызылтүш бигрәк сак.

Менә шуның өчен урманда сак булыгыз, балалар. Кош ояларына якын бара күрмәгез.

(92 сүз)

**Диктант № 3**

Яңа өйгә күчү

Керпе байтактан бирле куаклыкта яши иде. Кышкы авыр көннәрне дә шунда үткәрергә күнекте. Ул бер язгы сәяхәте вакытында урман юлын кичте дә түгәрәк аланга килеп чыкты. Монда тамырлары актарылып җирдә яткан агачка тап булды. Бу урында азык күп булганга керпе бик шатланды. Ул агач тирәли утлап йөрде, корт, бәҗәк белән сыйланды. Җиргә төртелеп торган тамырлар арасында йөрде. Тамыр күтәрткән мүкле кәс астындагы куышлыкны бик ошатты. Аңа коры-сары ташып җәйде. Керпе мондый өй турында күптән хыяллана иде. Ул юл аръягындагы куаклыктан давыл куптарган шушы агач төбенә күченеп килде.

Алан кояш нурына күмелә, хуш исле чәчәкләр җемелди. Керпе шушы аланда рәхәтләнеп яши башлады. Бирердә аңа бик тыныч иде. (107 сүз.)

*(М. Рафиковтан.)*

Бирем. Рәхәтләнеп, күптән, хыяллана сүзләрен төзелеше буенча тикшерергә.

**Диктант № 4**

Сертотмас кәҗә

Сертотмас үрдәкне беләбез инде, әле менә сертотмас кәҗә дә була икән.

Кыш көне безнең кәҗә бәтиләде. Без бик ялынып-ялваргач, әни бәтине өйгә алып керде. Ул кыш буе безнең белән бер табактан ашады,бергә уйнады,бер урында йоклады. Менә хәзер җәй көне артыбыздан калмый, безгә тагыла. Әнисен ияреп, көтүгә йөрсә дә ярый бит. Әллә ничә мәртәбә болынга кудык үзен, ә ул кача да кайта. Беркөнне келәткә бикләдек, мөгез очы белән келәне шудырып ачкан да капка астыннан чыккан. Теңкәбезгә тиде кәҗә бәтие. Футбол уйнаганда, тупны ике капкага да кертә. Качышлы уенында артыбыздан килә дә кычкырып тора. Эзләүче малай шунда ук таба безне. Нигә генә әнисе янында тотмадык икән шуны?

(107 сүз)

## Изложение текстлары

### Изложение № 1.

Күз җитеп килә иде. Балалар йортында тәрбияләнүчеләр бәрәңге җыярга бардылар. Бәрәңге бик уңган, игенчеләр үзләре генә җыярга өлгерә алмыйлар. Бәрәңге җыя торган машина юк иде әле ул чакта. Шуңа күрә булышырга килгән балаларны авылда бик яратып каршыладылар. Кайсы тимер көрәк, кайсы кәрзин я чиләк тотып клгән малайлар, кызлар иртәдән кичкә кадәр тырышып эшләделәр. Алар авыл малайлары белән узыша-узыша бәрәңге җыйдылар.

Зур-зур арбалар бер-бер артлы бәрәңге базына таба агылып торды. Ат йөртүче авыл  малайлары, үзара ярышып, бәрәңге ташыдылар. Һәр малай кичкә кадәр унар йөк бәрәңге илтергә тиеш иде. Алар, һәр йөкне илткән саен, тәртәгә акбур белән сызып, билге ясап бардылар.

(101 сүз)

(Хәбибуллина З.Н., Гыйләҗев И.Г. Изложениеләр җыентыгы)

План.

1. Балалар бәрәңге җыярга бардылар.
2. Авылда балаларны яратып каршыладылар.
3. Өмә күңелле узды.

### Изложение № 2.

Ноябрь чебешләре

Октябрь ахырында ярыйсы ук салкынайта. Төннәрен хәтта сулар **чирый**. Әмма монысы кояшлы һәм җылы көн иде. Һич көтмәгәндә чуар тавык килеп чыкты. Качкалак үзе генә түгел, артыннан җиде чебеш тә иярткән. Ишегалдында зур печән кибәне тора иде. Шунда кушылып кереп, чебешләр басып чыгарган.

Зөфәр дә уйга калды. Ни генә эшләтергә, кая гына куярга соң боларны ? Сыер абзарында юеш, тавыклар кетәклегендә аларга салкын... Ә чебешләр шундый матур, тереләр. Яшибез, зур үсәбез, дип торалар. Зөфәр берәр атна чамасы аларны өйдә тотып карарга булды.

Зөфәрнең әнисенең түземлеге төкәнде.

Бу сугыш чукмарларыңны теләсә кая куй... Кыш буе алар белән сугышып ятмабыз, - диде.

Ял көне иде. Зөфәр янына аның дусты Нәҗип тә кергән. Шунда малайлар пышыш-пышын гына нидер сөйләштеләр, ниндидер план кордылар, ахры. Зөфәр чоланнан балта, пычкы, чүкеч күтәреп чыкты. Малайлар сыер абзарының җылы, ышык почмагына чебешләр өчен кетәклек ясарга керештеләр. Көне буе баш күтәрми тырыштылар алар. Эшләрен хәтта Зөфәрнең әтисе дә килештерде.

Чебешләр үзләре дә бик килештерделәр бу кетәклекне, атна-ун көн эчендә күзгә күренеп үсеп киттеләр. Зөфәр аларны вакытында ашатты, вакытында эчертте. Яз башына алар барысы да бик матур тавыклар булып үсеп җиттеләр...

(179 сүз)

(Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре.-5-7 нче с-флары өчен)

***Чирый – су юка боз элпәсе белән каплана***

**Изложение № 3.**

Керпе

Бу хәл күп еллар элек булды. Без ул вакытта авылда тора идек. Җәйге эссе көн. Күктә бер болыт әсәре дә юк. Кояш кыздырыпмы-кыздыра. Авылның олысы-кечесе болында печән чаба. Минем абый да шунда китте. Өч-дүрт сәгатьтән төшке ашка кайтты. Карыйм, күлмәгенә нидер төргән. Күлмәккә барып тотынуым булды, кулымны чәнчеп, керпе килеп төште.

Шул көннән алып керпе бездә тора башлады. Баштарак читен булды, ахрысы, үзенә, әле караватастына, әле өстәл астына кереп кача иде. Соңга табаияләште, ашаганда яныбызга чыга, ашарга өмет итә. Без аңа иртән һәм кичен сөт эчертәбез, ә көндезге ашка ит бирәбез. Кич җиткәч, барыбыз да йокларга ятабыз. Тик керпе генә йокларга ашыкмый, тычкан ауларга йөри.

Салкын карлы бураннары белән кыш җитте. Аның артыннан матур яз килде. Керпе бездә яши бирде. Җәйге көннәрнең берсендә без аны өй алдына чыгардык. Әмма шул чыгудан керпебезне кабат күрә алмадык. Мөгаен, болынына киткәндер.

(139 сүз)

(Хәбибуллина З.Н., Гыйләҗев И.Г. Изложениеләр җыентыгы)

**План.**

1. Күптән булган вакыйга.
2. Керпенең безгә ияләшүе.
3. Керпенең яшәү тәртибе.
4. Керпенең иреккә китүе.

## Изложение № 4

Гөлләр үстерик

Гөлләр безнең тормышыбызга аерым бер ямь бирә. Безнең әниләр, әбиләр борын-борыннан гөл үстерү серләренә өйрәнгәннәр.

Гөл утырту өчен, барыннан да элек, туфракны дөрес сайларга кирәк. Бүлмә гөлләре үстергәндә, урман туфрагы, балчыклы кәс, черемә, торф һәм эре бөртекле елга комы катнашмасы файдаланыла. Гөл туфрагы азык матдәләренә бай, дым һәм һаваны яхшы үткәрә торган булырга тиеш.

Гөл үстерү өчен, юкәлек яисә каенлыктагы урман туфрагы әйбәт. Моның өчен, коелган яфрак катламын ачып, җирнең өске өлешен кырып алалар. Кәс туфрагын исә көтү йөри торган җирдән алырга мөмкин. Туфракка үлән тамырлары кермәсен. Аны гадәттә көзге якта әзерлиләр һәм коры урында саклыйлар.

Яз - бүлмә гөлләрен күчереп утырту чоры. Аерым очракта, гөл чүлмәге ватылса яки үсемлек “чирли” башласа, аны елның башка вакытларында да күчерәләр. Бер нәрсәне онытмаска кирәк : чәчәктә утырган яисә чәчәккә бөреләнгән гөлләрне күчереп утырту түгел, урыннарыннан кузгатырга да ярамый. Тиз үсә торган гөлләрнең күбесен ел саен, ә пальма, роза кебекләрен дүрт-биш елга бер мәртәбә генә күчереп утырталар.

Кешеләр кебек үк, гөлләр дә кайгыра, шатлана, елый беләләр. Үсеп торган гөлнең берәр ботагын сындырсаң, ул сызлана, рәнҗи, елый. Аның сынган ботагыннан яшь тама.

Гөл үзен тәрбияләп үстергән кешегә беркайчан да бурычлы булып калмый : елмаеп, рәхмәтен белдереп, шау чәчәк атып утыра.

(193 сүз)

(Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре.-5-7 нче с-флары өчен)

План.

1. Гөлләр үстерү – күркәм эш.

2. Гөлләр үстерү өчен туфрак сайлау.
3. Туфракны әзерләү.
4. Гөлләрне күчереп утырту.
5. Гөлләр рәхмәт әйтә beләләр.

**5 нче сыйныфка татар теленнән арадаш аттестация һәм агымдагы эшне тикшерү өчен методик материаллар һәм якынча бәяләү нормаларына аңлатма язуы.**

5 нче сыйныфларда татар теленнән арадаш аттестация эше өчен контроль диктант Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән үрнәк программага (Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010.) нигезләнеп төзелде. Дәреслек: Харисова Ч.М. Татар теле : татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5нче с-фы өчен д-лек/ Ч.М.Харисова, Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов. – Казан : татар.кит.нәшр., 2012.

Контроль диктант тексты 5 нче класста актив үзләштерелгән сүзләрдән тора, күләме 115 сүз.

**5 нче класс өчен татар теленнән арадаш аттестация эшенең максаты**

1. Сузыкларны һәм тартыкларны дөрес әйтү, сузык һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес яза белү күнекмәләрен үстерү. Сөйләмдә сүзләрне дөрес басым һәм тиешле интонация белән әйтә белү осталыгын һәм күнекмәләрен камилләштерү.
2. Сүзләрне иҗекләргә дөрес бүлү, юлдан юлга дөрес күчерү кагыйдәләрен аңлап куллану күнекмәләре булдыру.
3. Алфавиттан, төрле сүзлекләрдән дөрес һәм нәтиҗәле файдалана белү күнекмәләрен камилләштерү.
4. Сөйләмдә сүзләрне дөрес куллана белергә өйрәтү.
5. Телдән һәм язма сөйләмне синонимнар, фразеологизмнар белән баету, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрдән дөрес файдалана белү, сүзләрне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану күнекмәләрен үстерү.
6. Төрле теллрдән кергән сүзләрнең мәгънәләрен аңлап куллану һәм дөрес әйтү күнекмәләре булдыру.
7. Татар телендәге сүзләрне мәгънәле кисәкләргә бүләргә өйрәтү.
8. Кушымчаларның сүзгә ялгану тәртибен күзаллау һәм аларның төрләрен билгеләү осталыгы булдыру.
9. Сүзләргә фонетик, лексик, сүз төзелеше һәм ясалышы буенча шартлы билгеләр белән һәм телдән сөйләп анализ ясау күнекмәләре булдыру.

**Диктант**

**Керпе һәм аның балалары**

Быел керпе дөньяга биш бала китерде. Нәниләр ялангач тудылар, күзләре дә ачылмаган иде әле. Берничә сәгать эчендә алар ап-ак йомшак инәләр белән капландылар.

Керпе балаларын үстерү мәшәкате белән яшәде. Бераздан бәләкәй керпеләрнең күзләре ачылды, ак инәләре кучкыл һәм нык чәнечкеләр белән алышынды. Яшь керпеләр йомгакланып төрелергә һәм сүтелергә өйрәнделәр.

Әниләре яши торган алан керпе балалары өчен чын мәктәп иде. Керпе һәр көнне балаларын шунда алып чыга. Бөҗәкләр, коңгызлар эзләргә өйрәтә. Тычкан сукмагын да карыйлар. Гөмбәләр белән танышалар. Керпе кайчагында бака я елан белән очраша, аларны ботарлый. Яшьләр әниләре биргән дәрестән яшәү күнегүләре алалар.

Әниләре балаларына ай буе сөтен имезде. Ә көз якынлашкач, аларны мөстәкыйль тормышка озатты. Ана керпегә бик кыен булды. Чөнки аларның аерылышулары мәңгегә иде. (115 сүз)

Бирем: I вариантка **керпе** сүзенә,  II нче вариантка **тычкан** сүзенә фонетик анализ ясарга.

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

**Тестлар**

**ТЕСТ №1**

А1.Бер төрдән булган предметларны, затларны белдергән исемнәр

1) ялгызлык,  2)уртаклык,  3б) исем,  4) тамыр  була.

А2. Кайсы рәттә ялгызлык исемнәр бирелгән?

1) казан, авыл, сайлау, кеше,

2) “Сарман”, Саклаубаш, Саматов, ”Арзан” кибете

3) агач, җәнлек, мәктәп, оешма,

4) транспорт, автомобиль, клуб, педагог

А3.Исемнәр һәм фигыльләрдән торган рәтне билгеләгез.

1)тора, мин, ак, кыз,  2)матур, чибәр, бала, укый,

3) яза, укучы, класс, бара,  4)сиңа, безне, чаба, ул.

А4.Кайсы рәттәге  фигыльләр эшне белдерә?

1)сөенү, үсү, казу, язу,  2) бару, кайту, килү, китү,

3)авыру, яту, сизү, уку,   4)эшләү, кадаклау, кисү, төзү.

А5. “Мин” дигән мисез булыр. Син әйтмәдең, мин ишетмәдем. Сине тыңламаган җирдә эндәшми тор. Бу җөмләләрдә алмашлыклар нинди килешләрдә?

1)баш һәм төшем,  2)баш һәм иялек, 3)юнәлеш һәм чыгыш,  4)бернинди килештә дә түгел.

А6. Яхшы холык дошманыңны да дус итә. Бу җөмләдә ничә сүзтезмә?

а)1  ә)3 б)2  в)5.

А6.Бишенче йорт сүзтезмәсендә ияртүче сз кайсы?

1) бишенче 2)йорт

А7. Яхшы холык дошманыңны да дус итә. Бу җөмләдә грамматик нигез –

1.Яхшы холык.  2.Холык дус итә.  3.Дус итә.  4.Яхшы дус итә.

А8.Җөмлә кисәкләре ничәү?

а)2,  ә) 5, б)6,  в) 3.

А9.Баш кисәкләрдән торган җөмлә –

1)җыйнак җөмлә,  2) җәенке җөмлә, 3)хикәя җөмлә, 4)гади җөмлә була.

А10.Баш килештәге сүз җөмләдә һәрвакыт нинди кисәк була?

1) ия, 2) хәбәр, 3)аергыч, 4)хәл.

А11. Кемнең? нәрсәнең? нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл,  2)аергыч ,  3)тәмамлык.

А12. кайда? кайчан? ничек? күпме? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл,  2)аергыч ,  3)тәмамлык.

А13. Кемгә? нәрсәгә?кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл, 2)аергыч , 3)тәмамлык.

В1.***Ярышка китәсе малайлар дәрес беткәнен көчкә көтеп алдылар***. Бу җөмләгә синтаксик анализ ясагыз.

В2. Исем сүзен килеш белән төрләндерегез.

В3. Уку сүзен заман белән төрләндерегез.

## Тестлар

## ТЕСТ №1

А1.Бер төрдән булган предметларны, затларны белдергән исемнәр

1) ялгызлык, 2)уртаклык, 3б) исем, 4) тамыр була.

А2. Кайсы рәттә ялгызлык исемнәр бирелгән?

1)казан, авыл, сайлау, кеше,

2) “Сарман”, Саклаубаш, Саматов, ”Арзан” кибете

3)агач, җәнлек, мәктәп, оешма,

4)транспорт, автомобиль, клуб, педагог

А3.Исемнәр һәм фигыльләрдән торган рәтне билгеләгез.

1)тора, мин, ак, кыз, 2)матур, чибәр, бала, укый,

3) яза, укучы, класс, бара, 4)сиңа, безне, чаба, ул.

А4.Кайсы рәттәге фигыльләр эшне белдерә?

1)сөенү, үсү, казу, язу, 2) бару, кайту, килү, китү,

3)авыру, яту, сизү, уку, 4)эшләү, кадаклау, кисү, төзү.

А5. “Мин” дигән мисез булыр. Син әйтмәдең, мин ишетмәдем. Сине тыңламаган җирдә эндәшми тор. Бу җөмләләрдә алмашлыклар нинди килешләрдә?

1)баш һәм төшем,  2)баш һәм ияреек, 3)юнәлеш һәм чыгыш,  4)бернинди килештә дә түгел.

А6. Яхшы холык дошманыңны да дус итә. Бу җөмләдә ничә сүзтезмә?

а)1  ә)3 б)2  в)5.

А6.Бишенче йорт сүзтезмәсендә ияртүче сз кайсы?

2) бишенче 2)йорт

А7. Яхшы холык дошманыңны да дус итә. Бу җөмләдә грамматик нигез –

1.Яхшы холык.  2.Холык дус итә.  3.Дус итә.  4.Яхшы дус итә.

А8.Җөмлә кисәкләре ничәү?

а)2,  ә) 5, б)6,  в) 3.

А9.Баш кисәкләрдән торган җөмлә –

1)җыйнак җөмлә,  2) җәенке җөмлә, 3)хикәя җөмлә, 4)гади җөмлә була.

А10.Баш килештәге сүз җөмләдә һәрвакыт нинди кисәк була?

2) ия, 2) хәбәр, 3)аергыч, 4)хәл.

А11. Кемнең? нәрсәнең? нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл,  2)аергыч ,  3)тәмамлык.

А12. кайда? кайчан? ничек? күпме? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл,  2)аергыч ,  3)тәмамлык.

А13. Кемгә? нәрсәгә?кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? сорауларына нинди иярчен кисәк җавап бирә?

1)хәл,  2)аергыч ,  3)тәмамлык.

В1.***Ярышка китәсе малайлар дәрес беткәнен көчкә көтеп алдылар***. Бу җөмләгә синтаксик анализ ясагыз.

В2. Исем сүзен килеш белән төрләндерегез.

В3. Уку сүзен заман  белән төрләндерегез.

**Мөстәкыйль эшләр**

№1

**Яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны языгыз**

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Саңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Саңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Саңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Саңг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |